**Список литературы**

1. Юлдыбаева Г.В. Особенности поэтики башкирского народного эпоса «Урал-батыр» // Вестник Башкирского университета, 2012. — С. 1535-1538.
2. Ямалетдин М. Межа. Стихи, рубаи, поэмы-эпосы, дастаны. — Уфа: Китап, 2003. — 256 с. (На башк.яз.)
3. Урал батыр (эпос) [электронный источник]. URL: https://wikisource.org/wiki/%D0%A3%D1%80%D0%B0%D0%BB_%D0%B1%D0%B0%D1%82%D1%8B%D1%80_(%D1%8D%D0%BF%D0%BE%D1%81)

© Усманова А.А., Кунафин Г.С., 2022

УДК 398.1

**И.И. Фазлутдинов**, *г. Казань*

## РИВАЯТЬЛӘРНЕ ҺӘМ ЛЕГЕНДАЛАРНЫ СТРУКТУР-МОРФОЛОГИК ЯССЫЛЫКТА ТИКШЕРҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

***Аннотация:*** *В данной статье автор, опираясь на обширный список специальной литературы, анализирует проблему взаимоотношений мотива и сюжета в татарских преданиях и легендах. Подчеркивается отсутствие теории вычленения мотива из сюжета преданий и легенд, а также нормативного определения терминов «фольклорный мотив» и «фольклорный сюжет».*

***Ключевые слова:*** *предание, легенда, сюжет, мотив, фольклор, формула, объект, субъект.*

Риваятьләрнең һәм легендаларны структур-морфологик яссылыкта өйрәнү принциплары да әлегә кадәр ачыкланып бетмәгән. Риваятьләр системасыннан мотивларны аерымлап чыгару методикасы да әлегә кадәр башкарылмаган килеш кала бирә. Бу исә халык прозасы әсәрләренең сюжет составын тикшерүне дә авырлаштыра, чөнки сюжетлар үзләре үк катлаулы төзелеш структурасына ия. XX гасыр башында ук академик А.Н. Веселовский сюжет төшенчәсенә төрле мотивлар комплексы буларак билгеләмә бирә һәм бер үк мотивның төрле сюжетлар эченә кереп китә алуын күрсәтә [3; 1–133]. Шуннан чыгып, В.Я. Пропп халык прозасы әсәрләрен сюжетлар буенча түгел, ә беренче чиратта, мотивлар буенча өйрәнү кирәклеген ассызыклый [7; 18].

Шул ук вакытта, «мотив» төшенчәсенең асылын билгеләү дә әлегә кадәр хәл ителеп бетмәгән мәсьәлә булып кала. Русия фольклористикасында «мотив» терминына беренче булып А.Н.

Веселовский билгеләмә бирә. «Мотив дип мин тәүтормыш кешесе акылында туган төрле сорауларга образлы җавап бирүче иң гади хикәяләү берәмлеген аңлыйм», – ди ул [2; 500]. Автор шулай ук әлеге «хикәяләү берәмлеге»нең чагыштырмача тотрыклылыкка ия булуын билгели: «Мотив дип мин җәмгыятьнең тәүге чорларында табигать тарафыннан кеше алдына куелган сорауларга җавап бирүче, я булмаса чынбарлыкның аеруча чагу, мөһим булып тоелган яисә кабатланып торган күренешләрен аңда ныгытучы формуланы атыйм» [2; 494]. Ләкин фольклорда без тотрыклы, даими мотивлар белән генә түгел, ә үзгәреп торучан мотивлар белән дә очрашабыз. Җәмгыять, дөнья үзгәргән саен, риваять мотивлары да трансформация кичерә, мифологик сыйфатларын җуя, чынбарлыкка яраклаша. Шуңа да аларны формулага һич кенә дә тиңләп булмый. Моны В.П. Путилов бик дөрес билгеләп үтә һәм «фольклор әсәрләрендәге мотив – ул чагыштырмача мөстәкыйль, тәмамланган һәм элементар сюжет өлеше», – дигән фикергә килә [8; 143]. Югарыда китерелгән билгеләмәләр һәммәсе дә гомумфольклор мотивы төшенчәсенең эчтәлеген ачуга юнәлтелгәннәр.

«Риваять мотивы» билгеләмәсе беренче тапкыр В.П. Кругляшова хезмәтендә китерелә. «Мотив төшенчәсен без хикәяләнүче әйбернең тышкы кыяфәтен, үзенчәлеген, шаккаттыргыч детален телдән тасвирлаган, аның сыйфат, төсмерләрен ачып салган структур сюжет өлеше дип аңлыйбыз», – ди ул [5; 20]. Ләкин бу билгеләмәне дә камил дип әйтеп булмый, чөнки биредә риваять сюжетының структур компонентларын аерымлаганда шактый зур капма-каршылыклар килеп чыга, «мотив» терминының эчтәлеге бик киң итеп бирелә, аның чикләре билгеләнми.

В.Я. Пропп әкиятләрнең сюжет төзелешен тикшереп, «мотив бер өлешле дә, таркалмас та түгел... Ул аерым-аерым алганда вариантлаша торган мөстәкыйль элементларга таркала» дигән фикергә килә [5; 18]. Әйтергә кирәк, бу ачыш әкиятләрнең генә түгел, ә башка жанрларның – риваятьләрнең, легендаларның сюжет төзелешенә дә кагыла.

В.Я. Проппның фикерен үстереп, Н.А. Криничная мотивның структур элементлары итеп түбәндәгеләрне билгели: «субъект – хәрәкәт юнәлгән үзәк персонаж, объект; хәрәкәт үзе (гадәттә, бу – геройның вазыйфасы); хәрәкәтнең урын-вакыт кысаларын билгеләүче һәм шулай ук аның ни рәвешле алып барылуын ачыклаучы детальләр» [4; 18]. Мотивны шушы элементларның берлеге итеп карап, автор аңа түбәндәге билгеләмәне бирә: «мотив – ул эш-хәрәкәт билгеләүче рольгә ия булган, ә билгеләнүчеләр булып, нигез элемент-предикатка теге яки бу дәрәҗәдә йогынты ясаучы субъект, объект, хәрәкәт төсмерләре хезмәт иткән катлаулы структур берәмлек» [4; 19]. Шулай итеп, Е.М. Мелетинский кебек үк, Н.А. Криничная да мотивның ядросы – нигезе итеп хәрәкәт-

предикатны атый, аңа ярдәмче элементлар итеп субъект, объект, парациенсны исәпли [7; 146].

Без әлеге фикер белән тулысынча килешәбез, чөнки хәрәкәт, вакыйга һәр художестволы әсәрнең үзәгендә тора, башка структур берәмлекләр исә аны тулырак ачуда ярдәм итеп кенә киләләр.

Кызганычка каршы, И.К. Фазлетдинов билгеләвенчә, «татар һәм башкорт фольклористикасында халык прозасы әсәрләрен структур-морфологик яссылыкта өйрәнү эше башлангыч хәлендә генә» [1; 17]. Әдәбият теориясе сүзлекләрендә «фольклор мотивы» терминына аңлатмалар бөтенләй китерелми [9; 140]. Легенда һәм риваятьләрнең сюжет составларын тикшерүче галимнәр нигез итеп алардагы аерым мотивларны анализлауны алсалар да, бер генә хезмәттә дә «мотив» терминына анык кына билгеләмә очрамый [10; 97]. Бу исә терминологик буталчыклык тудыра һәм фәнни-тикшеренү эшен алып баруны авырлаштыра.

**Әдәбият исемлеге**

1. Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. – Казан: ТӘһСИ, 2021. – 296 б.

2. Веселовский А.Н. Историческая поэтика / под ред. В.М. Жирмунского. – Л.: Гослитиздат, 1940. – 647 с.

3. Веселовский А.Н. Поэтика сюжетов // Собрание сочинений. – Том II. – Выпуск 1. – С.–Пб., 1913. – С. 1–133.

4. Криничная Н.А. Русская народная историческая проза: вопросы генезиса и структуры / ответ. ред. В.К. Соколова. – Л.: Наука, 1987. – 232 с.

5. Кругляшова В.П. Жанры несказочной прозы уральского горнозаводского фольклора: учебное пособие для студентов филологического факультета. – Свердловск, 1974. – 166 с.

6. Мелетинский Е.М. Палеоазиатский мифологический эпос: цикл Ворона. – М.: Наука, 1979. – 229 с.

7. Пропп В.Я. Морфология сказки. – 2-е изд. – М.: Наука, 1969. – 168 с.

8. Путилов Б.Н. Мотив как сюжетообразующий элемент // Типологические исследования по фольклору: сб. статей памяти В.Я. Проппа (1895-1970). – М.: Наука, 1975. – С. 132-147.

9. Фазлетдинов И.К. Башкортстан татарлары фольклоры: тарихы һәм бүгенгесе («Башкортстан татарлары фольклоры» сериясе китапларын төзү тәҗрибәсеннән) // Фәнни Татарстан. – 2021. – Б. 133–142.

10. Фазлетдинов И.К. Фольклорчы галим Риф Мөхәммәтҗановның фәнни һәм педагогик эшчәнлеге // Фәнни Татарстан. – 2019. – Б. 94–99.

© Фазлутдинов И.И., 2022

УДК 821.512.145

**И.К. Фазлутдинов**, *г. Уфа*

# ӘНГАМ АТНАБАЕВ ШИГЪРИЯТЕНДӘ ТАТАР МИЛЛИ МОТИВЛАРЫ

***Аннотация:*** *В данной статье рассматривается развитие татарских национальных мотивов в творчестве Народного поэта Башкортостана Ангама Атнабаева в идейно-эстетическом содержании, системе поэтических образов, средствах поэтического отображения действительности. Автор приходит к выводу о неразрывной связи творчества поэта с татарским фольклором.*

***Ключевые слова:*** *поэт, поэзия, образ, фольклор, национальная проблема, лирика, произведение, лирический герой.*

Башкортстандагы татар шигъриятенең нигез ташларын салган әдипләрнең берсе – Башкортстанның халык шагыйре Әнгам Атнабаев. Шигърияттәге талантлы шәкерте Рим Идиятуллин билгеләвенчә, ул бер үк вакытта олы шагыйрь дә, көчле драматург та, коеп куйган журналист-публицист та, редактор да, оста тәрҗемәче дә булды [1; 8–11].

Татарлык хисе, милли гамь белән сугарылганлык шигырьләрендә ярылып ятса да, шагыйрьнең җыентыкларын төзүче Мәҗит Мөдәрисов сүзләре белән әйтсәк, Әнгам Атнабаевның «милли хәрәкәте халыкларны талаштыруга түгел, туганлаштыруга корылган иде» [3; 8]. Аның 1956 – 1985 еллар шигъриятендәге татарлык хисе Нажар Нәҗми иҗатындагы публицистик аһәң, милли изелүгә каршы протест лирикасы рәвешендә түгел, ә, беренче чиратта, татар халкының милли фольклорында, меңьеллык шигъриятендә төп урынны тоткан традицион образларга яңа, заманча эчтәлек салу аша гәүдәләнеш тапты. «Капка төбендә» (1956), «Яшь каен» (1957), «Туфрак» (1957), «Утыз яшь» (1958), «Кара икмәк» (1960), «Миннән башка» (1960), «Ак каеннар кая булганнар?» (1961), «Яшь егетләр чалгы яныйлар» (1961), «Сары сандугач, кара карлыгач» (1964), «Әкияттәге кебек» (1964) һ.б. башлангыч чор иҗатына караган шигырьләреннән үк татар шигъриятенең бөтен тарихы аша «кызыл җеп» булып сузылып килгән ак каен, туган җир, сары сандугач, гармун кебек традицион образлар, халык җырларының поэтикасы, әкиятләргә хас